КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 10 октябрь г.Казань № 1088

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, аның территориаль органнары һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларына (иң чик санына) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 7 март, 165 нче; 2019 ел, 17 май, 402 нче; 2019 ел, 13 июль, 572 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1006 нчы; 2020 ел, 18 февраль, 123 нче; 2020 ел, 27 апрель,

331 нче; 2020 ел, 9 июнь, 477 нче; 2020 ел, 24 июль, 622 нче; 2020 ел, 5 сентябрь, 790 нчы; 2020 ел, 21 ноябрь, 1042 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1230 нчы; 2021 ел, 14 май, 334 нче; 2021 ел, 30 июнь, 520 нче; 2021 ел, 17 август, 739 нчы; 2021 ел, 1 сентябрь, 803 нче; 2021 ел, 29 сентябрь, 927 нче; 2021 ел, 14 декабрь, 1229 нчы; 2021 ел, 30 декабрь, 1357 нче; 2022 ел, 24 февраль, 160 нчы; 2022 ел, 23 март, 259 нчы; 2022 ел, 7 апрель, 323 нче; 2022 ел, 11 апрель, 345 нче; 2022 ел, 13 август, 806 нчы; 2022 ел, 26 август, 901 нче, 2022 ел, 5 сентябрь, 960 нчы, 2022 ел, 6 октябрь, 1077 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларына (иң чик санына) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның 4 графасында «4» санын «8» санына алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «2. | Территориаль органнар (43 территориаль органга) | | 26 | җиңел автомобиль | 23 085 | 95 |
| | | | 129 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135»; |

9 һәм 10 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

«Барлыгы» юлында «198» саннарын «178» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин